**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423114, СЕЛО НИЖНЯЯ КАМЕНКА, УЛ.ЦЕНТРАЛЬНАЯ, Д. 51

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
423114 ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛЫҮЗӘК УРАМЫ, 51 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-35-21
Email: NkamCmn2@tatar.ru

**№ 64** **18.05.2022 ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2022 елның 31 мартындагы 103 номерлы «Муниципаль районның авыл җирлекләренә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү, үзгәрешләр кертү өлешендә вәкаләтләрне тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә.
2. Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгына муниципаль район башлыгы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.Р.Халиков